| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2020 Казан ш. № 572-30/тко-2020

«Меша» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 елга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Меша» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик тарифлар 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Меша» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 № 572-30/тко-2020
карарына кушымта

2021 елга «Меша» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны
күмүгә календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | |
|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Теләче муниципаль районы | | |
| 1 | «Меша» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте * | 136,91 | 146,92 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге